**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге башлыгы**

**карары**

**2024 елның 11 ноябре** **№68**

**«Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске-Йорт авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы **Зур Кукмара** авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 21 ноябренә 17 сәгать 30 минутка ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске Йорт авылында, Үзәк урам, 23 нче йортта үткәрергә билгеләргә.

2. 2024 елның 21 ноябренә 18 сәгать 30 минутка ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске Йорт авылында, Үзәк урам, 23 нче йортта үткәрергә билгеләргә.

3. 2024 елның 21 ноябренә 19 сәгать 30 минутка үзара ***салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын*** Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске Йорт авылында, Үзәк урам, 23 нче йортта үткәрергә билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы **Зур Кукмара** авыл җирлегенең Иске Йорт авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча

теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2025 елда үзара салымны 1500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

**тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау** (урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру);

**су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (су суырту башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, су суырту башняларын буяу, су суырту башняларын ремонтлау, артезиан кое насосларын алу һәм урнаштыру; яңа сүүткәргеч челтәрләрен төзү, ремонтлау, проект-смета документациясен әзерләү, килешү буенча хезмәтләр һәм эшләр өчен түләү);

**җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү** (Иске-Йорт авылында чишмәләр төзү, ремонтлау һәм территориясен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү);

**беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү** (янгын гидрантларын һәм комплектлаучыларны сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү);

**һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү** (Иске Йорт һәйкәлен төзү, ремонтлау һәм карап тоту, проект - смета документациясен эшләү);

**торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту** (юлларга вак таш җәю, юлларга вак таш җәеп, чокырларны төзекләндерү (ямочный ремонт), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Иске Йорт авылының урам-юл челтәрен карап тоту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру);

**торак пункт территориясен төзекләндерү** (балалар уен мәйданчыгын сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Иске-Юрт авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү);

**ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (саклау, ремонтлау, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Халык җыенның үткәрүгә җаваплы итеп Зур Кукмара авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәнәфиев